**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел.+7(84396) 2-58-00 тел./факс +7(84396) 2-58-42, email: Ispolkom.Cheremshan@tatar.ru; http://cheremshan.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.04.2022 ел **Чирмешән авылы** № 121

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына аларга карата генераль планнарны әзерләү кирәклеге булмау турында карарлар кабул ителгән авыл җирлекләре территориясендә урнашкан торак пунктларның чикләре турында белешмәләр өстәү өлешендә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы ФЗның 15 ст. 1 п. 15 пунктчасы, «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясындагы 1 өлеше, Чирмешән муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. 1 нче кушымтада күрсәтелгән, генераль планнарын әзерләү кирәклеге булмау турында карарлар кабул ителгән Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Бәркәтә, Югары Кәминкә, Ивашкино, Күтәмә, Мордва Афонькәсе, Түбән Кәминкә, Түбән Кармалка, Яңа Элмәле, Яңа Кади, Иске Кади, Иске Котыш, Иске Үтәмеш, Туймәт, Шешминка авыл җирлекләрендә урнашкан торак пунктларның чикләре турындагы белешмәләр белән тулыландыру өлешендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү проектын әзерләргә.

2. 1 нче кушымтада күрсәтелгән Бәркәтә, Югары Кәминкә, Ивашкино, Күтәмә, Мордва Афонькәсе, Түбән Кәминкә, Түбән Кармалка, Яңа Элмәле, Яңа Кади, Иске Кади, Иске Котыш, Иске Үтәмеш, Туймәт, Шешминка авыл җирлекләре территориясендә урнашкан торак пунктлары чикләре турында белешмәләр өстәү өлешендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына (2 нче кушымта) үзгәрешләр кертү проектын әзерләү буенча чаралар планын расларга.

3. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү проектын әзерләү буенча эшләрне финанслау, 1 нче кушымтада күрсәтелгән торак пунктларның чикләре турындагы белешмәләрне тулыландыру өлешендә, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

4. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында «pravo.tatarstan.ru» һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
җитәкчесе И.Н. Шәйдуллин

**1 нче кушымта**
Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
башкарма комитеты карары
белән расланган
13.04. 2022 ел № 121

**Генераль планнар әзерләү зарурлыгы булмау турында карар кабул ителгән Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы авыл җирлекләре исемлеге**

| № п/п | Авыл җирлеге исемлеге | Авыл җирлеге Советының генераль планнар әзерләү зарурлыгы булмау турында карары |
|---|---|---|
| 1 | Бәркәтә авыл җирлеге | 31.03.2022 №104 |
| 2 | Югары Кәминкә авыл җирлеге | 31.03.2022 №104 |
| 3 | Ивашкино авыл җирлеге | 31.03.2022 №104 |
| 4 | Күтәмә авыл җирлеге | 31.03.2022 №104 |
| 5 | Мордва Афонькәсе авыл җирлеге | 31.03.2022 №104 |
| 6 | Түбән Кәминкә авыл җирлеге | 31.03.2022 №104 |
| 7 | Түбән Кармалка авыл җирлеге | 31.03.2022 №104 |
| 8 | Яңа Элмәле авыл җирлеге | 31.03.2022 №104 |
| 9 | Яңа Кади авыл җирлеге | 31.03.2022 №104 |
| 10 | Иске Кади авыл җирлеге | 31.03.2022 №104 |
| 11 | Иске Котыш авыл җирлеге | 31.03.2022 №104 |
| 12 | Иске Үтәмеш авыл җирлеге | 31.03.2022 №104 |
| 13 | Туймәт авыл җирлеге | 31.03.2022 №104 |
| 14 | Шешминка авыл җирлеге | 31.03.2022 №104 |

**2 нче кушымта**

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
башкарма комитеты карары
белән расланган
13.04. 2022 ел № 121

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү проектын әзерләү буенча чаралар планы

| № п/п | Чаралар атамасы | Үтәү вакыты |
|---|---|---|
| 1 | 14-СП генераль планнарын әзерләү зарурлыгы булмау турында карар кабул итү | 1 эш көне |
| 2 | Чирмешән муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертүне әзерли башлау турында карар кабул итү | 1 эш көне |
| 3 | Җирле үзидарәнең вәкаләтле органы тарафыннан техник биремне раслау | 1 эш көне |
| 4 | Территориаль планлаштыру схемасын нигезләү буенча материалларны эшләү һәм өстәмәләр кертү өлешендә үзгәрешләр кертү проектын эшләүгә контракт төзү | 5 эш көне |
| 5 | Чирмешән муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасының торак пунктлары чикләрен, карталарын һәм текст материалларын формалаштыру | 2 ай |
| 6 | Татарстан Республикасы буенча «Росреестр ФКП» ФДБУда торак пунктлары чикләре урнашу урынының тасвирламаларын тикшерү | 7 эш көне |
| 7 | ФГИС ТПта территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү проектын урнаштыру һәм йөкләнелгән материаллардан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү. | 1 эш көне |
| 8 | Проект буенча яраштыру һәм җыелма бәяләмә алу үткәрү | 2 ай |
| 9 | Территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү проектын раслау | 5 эш көне |

| | | |
|---|---|---|
| 10 | ЕГРНга торак пунктлар чикләре турында белешмәләр кертү | 15 эш көне |

Килешенде:
инфраструктур үсеш
бүлеге начальнигы Х.С. Сәлахов

Әзерләде:
инфраструктур үсеш
бүлеге баш белгече Э.Б. Җиһаншина

Тикшерде:
район Советының
юридик бүлеге начальнигы Т.В. Рунова